Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советының утыз бишенче утырышы

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

5 июль, 2024 ел № 93

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге уставы нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Аерым салым түләүчеләр өчен исәпләнүче 2024 елның 1 гыйнварына җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч түләүгә ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә, аны каплау һәм (яисә) түләтү түбәндәге нигезләрдә мөмкин булмаган:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылганнан соң бер ел дәвамында мирасны кабул итмәгән очракта, вафат булган яисә үлгән дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар өчен исәпләнелә торган бурыч 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар узганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestresi.tatarstan.ru) һәм шулай ук Керәшен Сәрдәсе авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов